РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь 2019 ел г. Альметьевск № 2143

Әлмәт муниципаль районы
гомуми белем бирү учреждениеләренең
2020 елга норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлеше 11 пункты нигезендә, «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 3100 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең 2020 елга норматив чыгымнарны расларга (1 нче кушымта).
2. «2019 елга Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2222 номерлы карары 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көчен югалткан дип танырга.
3. «2020 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 02 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (З.Р. Шәйдуллина) финанслауны әлеге карарның 1 пункты нигезендә тәэмин итәргә.
4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ә.Б. Ханнанова) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
5. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә.

Зак. № 305-2000

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов